РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Буа шәһәре

№ 20-п

«07» март 2018нче ел.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында
коррупция һәм шундый белдерүләрне теркәү,
хәбәр итү тәртибен раслау турында

Буа муниципаль районында ришвәтчелеккә каршы көрәшне вакытында хәбәр итү , 2008 нче елның 25 нче октябрендә кабул ителгән "Коррупциягә каршы тору турында" №273-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасында 2006 нчы елның 4 нче маенда кабул ителгән "Коррупциягә каршы тору турында" 34 нче номерлы ТРЗ, 2006 нчы елның 2 нче маенда кабул ителгән "Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында"59 нчы номерлы Россия Федерациясенең федераль законы нигезендә

**Карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында коррупция һәм шундый белдерүләрне теркәү турында хәбәр итү тәртибен раслау. ( Кушымта 1)
2. 2011 нче елның 15 нче июнендә кабул ителгән 4-7 нче номерлы"Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында коррупция һәм шундый белдерүләрне теркәү турында хәбәр итү тәртибен раслау турында"гы Буа муниципаль районы башлыгы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында коррупция буенча гражданнарның язмача мөрәҗәгатьләре өчен "Ышаныч тартмалары"буенча эшче төркем составын расларга. ( Кушымта 2)
4. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында коррупция буенча гражданнарның "Ышаныч тартмалары"ннан алынган язмача мөрәҗәгатьләрен акт белән расларга. (Кушымта 3)
5. Буа муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру һәм мәгълүматны саклау буенча баш белгеченә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының рәсми сайтына әлеге карарны урнаштыру.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Буа муниципаль районы башлыгы ярдәмчесе З.А. Шәйхаттаровага йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы М.А. Җаббаров

Кушымта 1
Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районыны
башлыгы карарына
______________ № _______

**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында коррупция турында хәбәр итү һәм шундый белдерүләр белән эшләү тәртибен теркәү**

## 1. Гомуми хәле

1.1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районынында коррупциягә каршы көрәш халыкның нәтиҗәле хезмәттәшлеге максатыннан (алга таба – Комиссия) Буа муниципаль районы җитәкчелеге эшчәнлегенең нәтиҗәсен күтәрү, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районынында коррупциягә каршы көрәш буенча комиссия тарафыннан координациялә үтәртибендә эшләнде.

1.2.”Ышаныч телефоны”, “Ышаныч тартмалары” эшчәнлеге тәртибен Буа муниципаль районы башлыгы, коррупциягә каршы сораулар юнәлешендәге Комиссия рәисе билгели.

1.3. ”Ышаныч телефоны”, “Ышаныч тартмалары”ннан алынган Коррупциягә каршы килгән хәбәрләр турында комиссия утырышларында карала.

1.4. Коррупция турында хәбәрләр аноним һәм конкрет затлар, шулай ук физик затлардан да, юридик затлардан да булырга мөмкин.

## 2. Төп бурычлар

2.1. ”Ышаныч телефоны”, “Ышаныч тартмалары” эшчәнлегенең төп бурычлары:

1) Коррупция турында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен җирле үзидарә органнарында, муниципаль учреждениеләрдә (алга таба - мөрәҗәгать) карау һәм исәпкә алу;

2) Россия Федерациясе законында билгеләнгән дәүләт органнарына тиещле чараларны күрү һәм карар кабул итү өчен юнәлдерелгән мөрәҗәгатьләрне
карау, тиешле чараларны күрү һәм аларны кабул итү;

3) ”Ышаныч телефоны”, “Ышаныч тартмалары” аша кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау, бу шикаятьләрнең сәбәпләрен гомумиләштереп бетерү;

4) гариза бирүчегә җавап.

## 3. Коррупция турында хәбәр алу тәртибе, аларны карау һәм теркәү

3.1. ”Ышаныч телефоны” буенча Буа муниципаль районында булган коррупцияне җирле үзидарә органнарына (3-12-80) хәбәр итү. Ул районның рәсми сайтында даими урнаштырыла һәм массакүләм мәгълүмат чараларында теркәлә (алга таба Башлык ярдәмчесе). Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча журналга теркәү турында хәбәр итү һәм комиссиянең карарын чыгару.

3.2. “Ышаныч тартмалары” на һәр көнне 8.00дән 17 00 сәгатькә кадәр язмача мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

3.3. Коррупция турында “Ышаныч тартмалары” килгән хәбәрләрне комиссия тәкъдим итүе буенча гражданнарның күпләп җыелган урыннарында:

Буа муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы фойесында. Адресы: Буа шәһәре, Жорес урамы, 110а йорт.

Күп функцияле үзәкнең бинасы фойесында Адресы: Буа шәһәре, Космовский урамы, 108г йорты.;

“Тургай” сәүдә үзәге бинасында Адресы: Буа шәһәре, Р.Люксембург урамы, 122 нче А йортыннан алына һәм нәтиҗәләр ясала. .

- гражданнарның мөрәҗәгатьләре кимендә айга 1 тапкыр Башлык ярдәмчесе һәм комиссия әгъзалары катнашында“Ышаныч тартмалары”ннан алынган хәбәрләр нигезендә акт рәсмиләштерелә. (Кушымта №3). Актта алынган мәгълуматның датасы, акт төзүчеләрнең затлары, хатның саны, битләрнең саны, кыскача эчтәлеге, акт төзүчеләрнең имзалары;

Ел дәвамында мәгълүматларны алганнан һәм теркәгәннән соң Буа муниципаль районы башлыгына карарларны кабул итү һәм алга таба эшләү өчен җибәрелә.

3.4. Ришвәтчелек буенча “Ышаныч тартмалары” на Буа муниципаль районы Советы мөһере сугыла һәм Башлык ярдәмчесе имзасы куела.

3.5 Башлык мөрәҗәгатьләрне караганнан соң, Буа муниципаль районы Башлыгы ярдәмчесе Буа муниципаль районы Башлыгы резолюциясе нигезендә мөрәҗәгатьләрне гамәлгә ашыра.

3.6 Мөрәҗәгатьләр Федераль закон нигезендә 2006 нчы елның 2 нче маенда каралган “Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында”59 нчы номерлы ФЗ, “Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында” Татарстан Республикасының 2003 нче елның 26 номерлы ТРЗна таянып, билгеләнгән срокларда карала.

3.7 Квартал саен, айның 5нә кадәр, узган кварталга хисап ясала, Башлык ярдәмчесе язмача кергән мөрәҗәгатьләргә аналитик белешмә әзерли, Комиссия утырышына Комиссиядә фикер алышу өчен тәкъдим итә.

3.8. Башлык ярдәмчесе ришвәтчелеккә каршы Комиссиягә хәбәр итәр алдыннан Комиссия Рәисе белән алдан утырыш датасын килешә.

3.9. Ришвәтчелеккә каршы Комиссия мөрәҗәгатләрне караганннан соң карар кабул итә, яисә :

-ришвәтчелек турында эчке эшләр бүлегенә яки прокуратурага хәбәр итә;

- ришвәтчелек турында тикшерү комитетына хәбәр итә;

- район комиссиясенә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларын алыштыручы затларның вазифаи үз-үзен тотышы таләпләрен үтәү турында һәм мәнфәгать конфликтларын җайлаштыру тәкъдимнәре белән ришвәтчелек турында хәбәр җибәрә.

Комиссиянең ришвәтчелек турындагы хәбәрләрен бер үк вакытта берничә бүлеккә җибәрергә мөмкин.

## 4. Мөрәҗәгатьләрне теркәү һәм исәпкә алу

4.1. “Ышаныч телефоны”на һәм “Ышаныч тартмасы” (аннары – Журнал) на килгән мөрәҗәгатьләрне теркәү һәм исәпкә алу башлык ярдәмчесе тарафыннан башкарыла.

4.2. Журнал тегелгән, номерланган һәм киләсе реквизитлар булырга тиеш:

а) мөрәҗәгатьләрнең тәртип номеры;

б) “Ышаныч телефоны” һәм “Ышаныч тартмасы”ннан мөрәҗәгатьләрне алу вакыты;

в) мөрәҗәгатьченең исем, фамилиясе (аноним булса “аноним” билгесе куела);

г) мөрәҗәгатьченең адресы һәм телефон номеры;

д) мөрәҗәгатьнең кыскача эчтәлеге;

е) Буа муниципаль районы башлыгының резолюция эчтәлеге;

ж) кулланылган чаралар турындагы билге;

з) мөрәҗәгатьчегә җавапның чыгу номеры һәм датасы.

4.3. Ришвәтчелек белән бәйле булмаган сораулар кабул ителгән очракта , киләчәктә эшләү өчен Буа муниципаль районы Советы Аппаратына җибәрелә. Ришвәтчелек белән бәйле булмаган аноним хатлар шул ук тәртиптә тикшерелә, ләкин җавап бирелми.

4.4. Җирле үзидарә булегенең компетенция кысаларына кагылмаган мөрәҗәгатьләр килгәндә дәүләт идарәсенең компетенциясе кысаларындагы бүлеккә җибәрелә.

**5. Җаваплылык**

5.1. Мәгълүмат белән эшләүче вазифаи затлар «Ышаныч тартмасы» һәм «Ышаныч телефоны» аша алынган мәгълүматларның сакланышы өчен җаваплы һәм җаваплылык тота .

5.2. Әлеге тәртипне бозган вазифаи затлар, Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар җаваплылыкка тартыла.

Татарстан Республикасы Буа
муниципаль районы башлыгының
№ _______ «__»__________ карарына

3 нче кушымта

Акт
Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында
Ришвәтчелек юнәлешендәге сораулар буенча «Ышаныч тартмасыннан»
гражданнарның мөрәҗәгатьләрен алу турында

«__» ________ 20__ ел

«Язма корреспонденция өчен тартма ачыклыгы» Тәртибе эше буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында ришвәтчелек юнәлеше сораулары буенча эш группасы түбәндәге составта:
1.______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
2.______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
3.______________________________________________________________________
«__» ________ 20__ ел. _____сәг. _____мин.та
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
адресы буенча урнашкан ришвәтчелек юнәлешендәге сораулар буенча “Ышаныч тартмасы” ачылды

Билгеләгән:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(тартманың бозылган яки бозылмаган булуы, гражданнар мөрәҗәгатьләре)

Акт ______биттә _____ данәдә төзелде.

эшче төркем әгъзалары имзасы:
______________________/____________________________/
______________________/____________________________/
______________________/____________________________/
Гражданнар мөрәҗәгатьләре исемлеге

| № п/п | Мөрәҗәгать кемнән килгән | Кире адрес | Искәрмә |
|---|---|---|---|

Татарстан Республикасы Буа
муниципаль районы башлыгының
№ _______ «__»__________ карарына

2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районың ришвәтчелек юнәлешендәге сораулары буенча «Ышаныч тартмасы" ннан мөрәҗәгатьләрне алучы эшче төркемнең составы

Алимов Азат Мирсәет улы - Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе, эшче төркем җитәкчесе;

Шәйхаттарова Зөлфия Әсхәт кызы - Буа муниципаль районының ришвәтчелеккә каршы сораулар буенча башлык ярдәмчесе, эш төркеменең сәркатибе;

Әһлиуллина Венера Ибраһим кызы - МКО "Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы исәп-контроль платасы"ның рәисе урынбасары, эш төркеме әгъзасы.